**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ                                                    КАРАР

«____» _____________ 2024 ел                                № ____

**2025 елның 1 гыйнварына Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында**

Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Рәисе Ф.и. Гыймадиевның «01.01.2025 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. 01.01.2025 елга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше буенча канәгатьләнерлек эшне билгеләп үтәргә.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны 01.01.2025 елга керемнәр буенча 915351,2 мең сум һәм чыгымнар буенча 900591,9 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артып китүе белән (муниципаль район бюджеты профициты) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә 14759,3 мең сум күләмендә расларга.
3. 2025 елның 1 гыйнварына Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше буенча түбәндәге күрсәткечләрне расларга:

- Әтнә муниципаль районы бюджетының үтәлеше турында 01.01.2025 елгы хисап;
- әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәре;
- әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнары;
- Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнары;
- Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнары әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә максатчан статьялар (Әтнә муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага кертелмәгән юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча;
- Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе                                        Г.Г. Хәкимов